СОВЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**
**16.08.2016**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 117**

Зеленодольск муниципаль районы муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкләүне түләү тәртибе турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Советының 2015 елның 28 октябрендәге 19 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкләүне түләү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге эчтәлекле 9 пункт өстәргә:

“9. Бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкләү әлеге нигезләмәнең 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләр туктатылган очракта, 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 35 статьядагы 16 өлешнең җиденче абзацында, 36 статьядагы 6.1 өлеше, 6 өлешнең 2.1, 3, 6 - 9 пунктларында, 40 статьядагы 10.1 өлешендә, 10 өлешнең 5 - 8 пунктларында, 7.1 өлешендә, 73 статьядагы 1 һәм 2 өлешләрендә каралган нигезләр буенча түләнми”.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) Интернет челтәрендә урнаштырырга.

**Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы,**
**Совет рәисе** **А. В. Тыгин**